| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» февраль 2023 ел г. Альметьевск № 438

«2019-2023 елларга Әлмәт муниципаль районының сәламәтлек саклау өлкәсендә кадрлар сәясәте» муниципаль программасын раслау турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 28 маендагы 1029 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Төзәтүләр тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2019-2023 елларга Әлмәт муниципаль районының сәламәтлек саклау өлкәсендә кадрлар сәясәте» муниципаль программасын раслау турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 28 маендагы 1029 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 23 декабрендәге 2244 номерлы, 2020 елның 25 декабрендәге 1943 номерлы, 2021 елның 23 декабрендәге 1898 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада

программа паспортында «Программа күләме һәм финанслау чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программа күләме һәм финанслау чыганаклары | Финанслауның гомуми күләме программа буенча 3 066,5 мең сум тәшкил итә.<br>2019 ел - 818,0 мең сум,<br>2020 ел - 506,5 мең сум,<br>2021 ел. - 324, 0 мең сум<br>2022 ел. - 444,0 мең сум,<br>2023 ел. - 974, 0 мең сум,<br><br>Искәрмә: әлеге Программаны гамәлгә ашыруга бәйле чараларны финанслау Әлмәт муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына расланган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырыла. Программаны гамәлгә ашыруга тотыла торган акчалар күләме аны гамәлгә ашыру срогы дәвамында район бюджеты, инфля- |

Зак. № 305-2000

| | |
|---|---|
| | ция процесслары һәм Әлмәт муниципаль районы территориясендә икътисадый вазгыять мөмкинлекләреннән чыгып төгәлләштерелә һәм төзәтелә. |

4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Программаны ресурс белән тәэмин итүне нигезләү

Программа чараларын финанслауның төп чыганагы булып Әлмәт муниципаль районы бюджеты акчалары тора.

Программаны Әлмәт муниципаль районы бюджеты хисабына финанслауның гомуми күләме 3 066,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Программаны гамәлгә ашыру еллары буенча:

2019 ел - 818,0 мең сум,
2020 ел - 506,5 мең сум,
2021 ел. - 324,0 мең сум,
2022 ел. - 444,0 мең сум,
2023 ел. - 974, 0 мең сум.»

муниципаль программага 1 нче кушымтада:

«Әлмәт муниципаль районы медицина оешмаларында кадрлар кытлыгын бетерүгә юнәлдерелгән чаралар» 1 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Әлмәт муниципаль районы медицина оешмаларында кадрлар кытлыгын бетерүгә юнәлдерелгән чаралар | | | | | | | | | |
| 1. | Студентларның 50/50 программасы буенча медицина югары уку йортларында белем алуга грант | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты; Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча сәламәтлек саклау идарәсе (килешү буенча) | ел саен | 1794,0 (муниципаль бюджет) | 498,0 | 324,0 | 324,0 | 324,0 | 324,0 |
| 2. | Әлмәт муниципаль районының сәламәтлек саклау өлкәсендә аккредитациядән соң эшкә урнаштырылган һәм кимендә 1 ел эшләгән белгечләргә кирәкле белгечлекләр буенча ординатурада укырга грант | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты; Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча сәламәтлек саклау идарәсе (килешү буенча) | ел саен | 170,0 (муниципаль бюджет) | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 170,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Сәламәтлек саклау учреждениесенең беренчел звеносына аккредитациядән соң эшкә урнаштырылган яшь белгечкә субсидияләр | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты; Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча сәламәтлек саклау идарәсе (килешү буенча) | ел саен | 480,0 (муниципальный бюджет) | 240,0 | 60,0 | 0,0 | 40,0 | 140,0 |
| 4. | ординатурада укыганнан соң сәламәтлек саклау учреждениесенә эшкә урнаштырылган яшь белгечкә субсидияләр | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты; Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча сәламәтлек саклау идарәсе (килешү буенча) | ел саен | 360,0 (муниципальный бюджет) | 80,0 | 40,0 | 0,0 | 80,0 | 160,0 |
| 5. | Медицина югары уку йортларында максатчан юнәлеш буенча укучы студентларга субсидия рәвешендә түләүләр | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты; Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча сәламәтлек саклау идарәсе (килешү буенча) | ел саен | 232,5 (муниципаль бюджет) | 0,0 | 52,5 | 0,0 | 0,0 | 180,0 |
| 6. | Медицина югары уку йортларында максатчан юнәлеш буенча ординатурада укучыларга субсиия рәвешендә түләүләр | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты; Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районы буенча сәламәтлек саклау идарәсе (килешү буенча) | ел саен | 30,0 (муниципаль бюджет) | 0,0 | 30,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |

«Барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Барлыгы: | | | 3 066.5 | 818,0 | 506,5 | 324,0 | 444,0 | 974,0 |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов